КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 21 февраль г.Казань № 171

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмалары һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 25 апрель, 323 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 18 июль, 611 нче; 2012 ел, 31 декабрь, 1183 нче; 2013 ел, 30 гыйнвар, 48 нче; 2013 ел, 11 май, 313 нче; 2013 ел, 29 июнь, 455 нче; 2014 ел, 10 гыйнвар, 2 нче; 2014 ел, 17 гыйнвар, 20 нче; 2014 ел, 28 май, 362 нче; 2014 ел, 25 август, 613 нче; 2014 ел, 6 октябрь, 726 нчы; 2014 ел, 10 октябрь, 752 нче; 2014 ел, 29 декабрь, 1050 нче; 2015 ел, 4 август, 565 нче; 2015 ел, 30 декабрь, 1025 нче; 2016 ел, 2 сентябрь, 611 нче; 2016 ел, 23 декабрь, 983 нче; 2017 ел, 18 май, 292 нче; 2017 ел, 27 сентябрь, 731 нче; 2017 ел, 26 октябрь, 809 нчы; 2017 ел, 31 октябрь, 827 нче; 2017 ел, 11 ноябрь, 885 нче; 2018 ел, 22 гыйнвар, 27 нче; 2018 ел, 26 апрель, 293 нче; 2018 ел, 29 октябрь, 953 нче; 2018 ел, 27 декабрь, 1247 нче; 2019 ел, 13 июль, 578 нче; 2019 ел, 28 август, 730 нчы; 2019 ел, 18 октябрь, 938 нче; 2019 ел, 29 октябрь, 967 нче; 2019 ел, 20 декабрь, 1176 нчы; 2020 ел, 28 май, 433 нче; 2020 ел, 29 июнь, 539 нчы; 2020 ел, 8 июль, 568 нче; 2021 ел, 4 февраль, 54 нче; 2021 ел, 26 июль, 645 нче; 2021 ел, 16 август, 737 нче; 2021 ел, 23 сентябрь, 903 нче; 2021 ел, 30 октябрь,1030 нчы; 2022 ел, 30 май, 499 нчы; 2022 ел, 20 июнь, 587 нче; 2022 ел, 15 июль, 683 нче; 2022 ел, 12 август, 797 нче; 2022 ел, 14 сентябрь, 1002 нче; 2022 ел, 20 сентябрь, 1018 нче; 2022 ел, 11 октябрь, 1093 нче; 2022 ел, 8 ноябрь, 1184 нче; 2022 ел, 21 ноябрь, 1249 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан

Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары ведомство буйсынуындагы медицина оешмаларының һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы аерым типлаштырылмаган учреждениеләрнең хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Гомуми практика буенча медицина шәфкать туташы», «паллиатив ярдәм буенча медицина шәфкать туташы», «профилактика буенча медицина шәфкать туташы», «тернәкләндерү буенча медицина шәфкать туташы» вазифасын биләгән, «Шәфкать туташы эше» әзерлек юнәлеше буенча бакалавриат бетергән югары белемле хезмәткәрләрнең база оклады 17 900 сум күләмендә билгеләнә.»;

6.3 пунктына түбәндәге эчтәлекле 6.3.14 пунктча өстәргә:

«6.3.14. Йогышлы авыру хастаханәләре:

| Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәте өчен түләү төркеме | Төп персоналга керә торган хезмәткәрләрнең штат саны |
|---|---|
| 1 | 300 дән артык |
| 2 | 100 дән 200 гә кадәр |
| 3 | 100 гә кадәр»; |

6.4 пунктта:

6.4.14 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.4.14. Бала йортлары җитәкчеләренең база һәм вазыйфаи окладлары, хезмәт өчен түләү төркеменә карап, түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәте өчен түләү төркеме | База оклады, сум | Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәте өчен түләү төркемнәре буенча коэффициент күрсәткече | Вазыйфаи оклад, сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 35 500 | 1,00 | 35 500 |
| 2 | 35 500 | 0,95 | 33 725 |
| 3 | 35 500 | 0,90 | 31 950 |
| 4 | 35 500 | 0,85 | 30 175 |
| 5 | 35 500 | 0,80 | 28 400 |
| 6 | 35 500 | 0,65 | 23 075 |

Бала йортлары җитәкчеләренең вазыйфаи окладларын билгеләгәндә, башкарыла торган эшләрнең катлаулылыгын һәм мөһимлеген, әлеге учреждениеләр эшчәнлеге үзенчәлекләрен исәпкә алып, вазыйфаи окладка карата 1,25 күләмендә арттыру коэффициенты кулланыла.

Вазыйфаи окладка карата әлеге арттыру коэффициентын куллану компенсация һәм стимул бирү характерындагы түләүләрне исәпләү өчен яңа вазыйфаи окладны барлыкка китерми.»;

түбәндәге эчтәлекле 6.4.16 пунктча өстәргә:

«6.4.16. Йогышлы авыру хастаханәләре җитәкчеләренең база һәм вазыйфаи окладлары, хезмәт өчен түләү төркеменә карап, түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәте өчен түләү төркеме | База оклады, сум | Дәүләт оешмалары җитәкчеләренең хезмәте өчен түләү төркемнәре буенча коэффициент күрсәткече | Вазыйфаи оклад, сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 36 900 | 1,00 | 36 900 |
| 2 | 35 500 | 0,95 | 33 725 |
| 3 | 35 500 | 0,90 | 31 950 |

«Профессор А.Ф.Агафонов исемендәге Республика клиник йогышлы авырулар хасханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе җитәкчеләренең вазыйфаи окладларын билгеләгәндә, башкарыла торган эшләрнең катлаулылыгын һәм мөһимлеген, әлеге учреждениеләр эшчәнлеге үзенчәлекләрен исәпкә алып, вазыйфаи окладка карата 1,25 күләмендә арттыру коэффициенты кулланыла.

Вазыйфаи окладка карата әлеге арттыру коэффициентын куллану компенсация һәм стимул бирү характерындагы түләүләрне исәпләү өчен яңа вазыйфаи окладны барлыкка китерми.»;

6.5 пунктның өченче абзацында «психиатрия диспансерлары (хастаханәләр, шифаханәләр)» сүзләреннән соң «, бала йортлары, «Профессор А.Ф.Агафонов исемендәге Республика клиник йогышлы авырулар хасханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе» сүзләрен өстәргә;

әлеге Нигезләмәнең 12 нче кушымтасында:

57 юлның 1 графасында «57» саннарын «70» саннарына алмаштырырга;

58 юлның 1 графасында «58» саннарын «71» саннарына алмаштырырга;

әлеге Нигезләмәнең 13 нче кушымтасындагы 50 юлның 4 графасында «4» санын «20» саннарына алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт яшьләр сәясәте оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 14 август, 665 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 21 июнь, 505 нче; 2020 ел, 31 гыйнвар, 54 нче; 2021 ел, 26 июль, 645 нче; 2021 ел, 30 октябрь, 1030 нчы; 2022 ел, 9 февраль, 102 нче; 2022 ел, 1 апрель, 304 нче; 2022 ел, 20 июнь, 587 нче; 2022 ел, 14 сентябрь, 1002 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы ведомствосы буйсынуындагы дәүләт яшьләр сәясәте оешмалары һәм аерым типик булмаган оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә, II бүлекнең 4 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәп, үзгәреш кертергә:

«Созвездие – Йолдызлык» иҗади сәләтле балаларга һәм яшьләргә ярдәм күрсәтү буенча республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең «Созвездие – Йолдызлык» арт-резиденциясе өчен:

«труппа мөдире», «вокал буенча репетитор», «балет артисты», «драма артисты», «симфоник, камера, эстрада-симфоник, тынлы оркестрлар, халык уен кораллары оркестры» вазыйфаларын биләүче һәм түбәндәгеләргә ия:

квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәри белемле, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белемле, тулы булмаган югары белемле хезмәткәрләрнең база оклады 16 149 сум тәшкил итә;

аттестацияне уңышлы үткән затка «бакалавр», «магистр» яки «белгеч» квалификациясен бирүне раслый торган югары белемле хезмәткәрләрнең база оклады 18 382 сум тәшкил итә;

«баш дирижер», «баш режиссер», «әдәбият-драматургия өлеше җитәкчесе», «сәнгатьчә кую өлеше мөдире», «музыка өлеше мөдире» вазыйфасын биләүче һәм түбәндәгеләргә ия:

квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәри белемле, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белемле, тулы булмаган югары белемле хезмәткәрләрнең база оклады 23 248 сум тәшкил итә;

аттестацияне уңышлы үткән затка «бакалавр», «магистр» яки «белгеч» квалификациясен бирүне раслый торган югары белемле хезмәткәрләрнең база оклады 26 498 сум тәшкил итә.».

3. Бу карарның гамәле 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин